РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
ЭНТУГАНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯНТУГАН
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

08 июль 2022 ел　　　　　　　　　　　　　　　　№ 48-1

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының
Янтуган авыл җирлегендә җирләрдән файдалану
һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм
өстәмәләр кертү турында карар хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты, Буа муниципаль районының Янтуган авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Янтуган авыл җирлеге советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Янтуган авыл җирлеге Советының 2013 елның 20 февралендәге 1-28 номерлы «Буа муниципаль районы Янтуган авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре турында» карары белән расланган Буа муниципаль районы Янтуган авыл җирлегеннән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре турында» карары белән расланган Буа муниципаль районы Янтуган авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә (28.06.2016 № 16-1, 21.09.2016 № 19-1, 23.09.2017 № 38-1, 11.02.2019 № 60-5, 22.06.2021 № 22-1, 01.03.2022 № 38-2, 04.05.2022 № 44-1 номерлы карарлары редакциясендә) (алга таба-Кагыйдә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 1 статья:

24 абзацны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Торак кодексының 15 статьясындагы 6 өлеше нигезендә, Россия Федерациясе Торак кодексының 36 статьясындагы 1 өлешенең 1-3 пунктларында күрсәтелгән мөлкәтне үз эченә алган ике һәм аннан күбрәк фатирдан торган бина күпфатирлы йорт дип танылa. Күпфатирлы йорт шулай ук торак булмаган биналарның һәм (яки) машина-урыннарның аерым милекчеләренә караган, мондый күп фатирлы йортның аерылгысыз өлеше булып торган урыннарын үз эченә ала.».

2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Янтуган авыл җирлеге Советының «Буа муниципаль районы Янтуган авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре турында» 2013 елның 20 февралендәге 1-28 номерлы карары белән расланган (28.06.2016 № 16-1, 21.09.2016 № 19-1, 23.09.2017 № 38-1, 11.02.2019 № 60-5, 22.06.2021 № 22-1, 01.03.2022 № 38-2, 04.05.2022 № 44-1 номерлы карарлар редакциясендә) Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Янтуган авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең яңа редакциясен хупларга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/), шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http://buinsk.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Буа муниципаль районы Янтуган авыл
җирлеге башлыгы, Совет рәисе Р.А. Замалтдинов